СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ТУКТАРОВО-УРДАЛИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ТУКТАР-УРДАЛАСЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2023 елның 14 мартыннан №8

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2013 елның 05 декабрендәге 25 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

2022 елның 29 декабрендәге 612-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2013 елның 05 декабрендәге 25 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм тезелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

12 статьяның 5 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«әгәр мондый килешү РФ Шәһәр төзелеше кодексының 40.1 маддәсендә каралган булса, капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше кыяфәтен килештерү.»;

19 статьяның 2 өлешендә «бер ай һәм өч айдан артык» сүзләрен «ундүрт көн һәм утыз көннән артык» сүзләренә алмаштырырга.

2.Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Туктар Урдаласы авылы, Совет урамы, 98 йорт административ бинада, Совет урамы, 103 йорт мәдәният йорты бинасында, Карагай авылы, Тельман урамы, 31 йорт КФҮ бинасы адресы буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

«Туктар-Урдаласы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Г.Ә.Әхмәтова